ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.07.2022 г. Заинск №336

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 27 февралендәге 124 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Полиция хезмәткәрләренең балаларына социаль ярдәм күрсәтү максатында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 27 февралендәге 124 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 2 бүлекнең 2.1.6 пунктында «полиция хезмәткәрләренең балалары» сүзләрен өстәргә;
1.2. 5 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "ТҮЛӘҮСЕЗ ТУКЛАНУ, ТАШЛАМАЛЫ ТУКЛАНУ ТӘРТИБЕ"
1.3. түбәндәге эчтәлекле 5.1 пунктын өстәргә:
«Полиция хезмәткәрләренең мәктәптә укучы балалары өчен туклануга түләү күләме 50 процентка кими. Моның өчен кирәк:
- ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) язмача гариза;
- полиция хезмәткәре булган атаның, ананың эш урыныннан белешмә ".

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 27 февралендәге 124 номерлы Татарстан

Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 23 маендагы 250 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42